**Беләсезме....**

**Җәннәт әхелләренең күбесе факыйрләр, җәһәннәм әхелләренең күбесен хатыннар тәшкил итәр.**

Пәгамбәребез әйтте: “Җәннәттә мин күбрәк факыйрләрне күрдем, җәһәннәмгә карагач анда күпчелеге хатыннар иде”,-диде. (Фатх-аль-Бари 6/318)

**Кеше үлгәч аңа иртә-кич җәннәттәге яки җәһәннәмдәге урыны күрсәтеләчәк.**

Пәйгамбәребез әйтте: “Кеше үлгәч аңа иртә-кич җәннәттәге яки җәһәннәмдәге урыны күрсәтеләчәк. Әгәрдә кеше җәннәткә лаек булса, үлгәннән соң аңар җәннәттәге урыны күрсәтелер һәм “Менә синең киләчәктәге урының”,-дип әйтелер. Әгәрдә кеше җәһәннәмгә лаек булса, үлгәннән соң аңар җәһәннәмдәге урыны күрсәтелер һәм “Менә синең киләчәктәге урының”,-дип әйтелер. (шарх Сахих Муслим (17/300)

**Җәннәт ишекләренең күгәннәренең арасы Мәккә шәһәре белән Басра шәһәре арасы кебек булыр.**

Пәйгамбәребез әйтте: “Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, җәннәт ишекләренең күгәннәренең арасы Мәккә шәһәре белән Басра шәһәре арасы кебек”.(Аль-бидайа ва-н-нихайа 2/221)

**Иң беренче җәннәткә керәчәк кеше безнең пәйгамбәребез булачак.**

Пәйгамбәребез әйтте: “Мин җәннәт ишекләрен кагучы иң беренче кеше булырмын” (Муслим)

**Җитмеш мең кеше җәннәткә хисапсыз керер.**

Пәйгамбәребез әйтте: “Минем өммәтемнән җитмеш мең кеше җәннәткә хисапсыз керер. Аларның йөзләре тулган ай кебек, йөрәкләре барысының да бер төрле булыр. Мин Раббымнан бу кешеләрнең санын арттыруын сорадым, ул миңа һәр меңе саен тагын җитмеш мең бирде. (Ахмад)

**Кәүсәр елгасы ярлары хушбуйдан, ташлары енҗедән булыр**.

Пәйгамбәребез әйтте: "Миңа "Кәүсәр" елгасы бирелде. Мин аның ярларында мәрҗәннән булган шатырларны күрдем. Әлеге шатырлар урнашкан җир хушбуйдан, ташлары енҗедән иде.

**Җәннәттә иң дәрәҗәле урын "вәсилә" дип аталыр.**

Пәйгамбәребез әйтте: "Җәннәттә иң дәрәҗәле урын "вәсилә" дип аталыр. Әлеге урынны догаларыгызда минем өчен сорагыз."

**Абдуррахман Хабибуллин**